**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 август № 541

г. Казань

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре» 2016 ел, 31 май, ПУ-491 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәне һәм аның составын (карарга теркәләләр) расларга.

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча 152 107,0 сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 30 берәмлек итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына рәиснең ике урынбасарын булдыруны рөхсәт итәргә.

4. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында тәкъдимнәр кертергә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 ел, 20 ноябрь, ТРЗ-97 нче Татарстан Республикасы Законында күздә тотылган акча чикләрендә әлеге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 17 сентябрь, 472 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел,

7 август, 408 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 28 май, 343 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 4 октябрь, 781 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2011 ел, 8 июль, 555 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 21 сентябрь, 783 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2012 ел, 8 февраль, 92 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе мәсьәләләре» 2006 ел, 7 август, 408 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 15 февраль, 92 нче.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 август, 541 нче карары белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм җайга салу, Татарстан Республикасы территориясендә архив эше өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен һәм компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тармакара хезмәттәшлекне тормышка ашыру, шулай ук архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны тикшерүдә тоту функцияләрен башкаруга вәкаләтле тармакара компетенциядәге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.

1.2. Дәүләт комитеты үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә, архив эше өлкәсендәге норматив һәм методик документларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Дәүләт комитеты үзенең эшчәнлеген турыдан-туры ведомство буйсынуындагы оешмалары белән һәм алар аша, Федераль архив агентлыгы һәм башка федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

1.4. Дәүләт комитеты юридик зат булып тора, мөстәкыйль баланска, аңа оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәткә ия, үз исеме һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте белән мөһергә һәм бланкларга, үзенең эшчәнлеге өчен кирәкле башка мөһерләргә, бланкларга ия, банк учреждениеләрендә законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган исәп-хисап һәм башка счетлары (валюта счетын кертеп) була.

1.5. Дәүләт комитетына йөкләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.6. Дәүләт комитетының тулы рәсми исеме – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

Кыскартылган рәсми исеме – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты.

1.7. Дәүләт комитетының урнашкан урыны (юридик адресы):

420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль ур., 2/6 йорт.

## 2. Дәүләт комитетының бурычлары

Дәүләт комитетының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1.1. Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

2.1.2. Законнар нигезендә гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру;

2.1.3. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүдә катнашу;

2.1.4. Компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә норматив хокукый актлар эшләү һәм кабул итү;

2.1.5. Үз компетенциясе чикләрендә архив эше турындагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары үтәлешенә төбәк контролен тормышка ашыра;

2.1.6. «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» 1994 ел, 29 декабрь, ФЗ-77 нче Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 ел, 18 гыйнвар, ТРЗ-5 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен тапшыруны тикшерүдә тота.

## 3. Дәүләт комитетының функцияләре

3.1. Дәүләт комитеты архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашыру өчен җавап бирә (01.15.03*).

3.2 Дәүләт комитеты үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән – бюджет процессы (Татарстан Республикасы бюджеты һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлары) белән

---

* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча кодны билгеләү

идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.1*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – Татарстан Республикасы милкендә булган күчемсез мөлкәттән (бина, корылма), транспорттан, җиһаздан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07.01*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

энергия һәм ресурслар саклау белән идарә итү (01.14*);

якын һәм ерак чит илләр белән икътисадый, мәгълүмати һәм мәдәни элемтәләрне саклау, шул исәптән ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә (01.03.2*);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән – мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм файдалану) өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диндә булган дини берләшмәләр арасындагы үзара аңлашуны һәм түземлекне ныгытуга булышлык күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.03*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген яраштыру һәм хокукый тәэмин итү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) функциясен гамәлгә ашырганда (02.04.01*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.05.02*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән – табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән – дәүләт-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр өлкәсендә инвестицион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.18*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт өчен түләүне, хезмәт мөнәсәбәтләрен, турыдан-туры хезмәткә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.13.01*);

хезмәтне саклау белән идарә итү (01.13.02*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

мәгълүматлаштыру белән идарә итү (01.15*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03*).

3.3. Дәүләт комитеты үз компетенциясе чикләрендә әлеге Нигезләмәнең 3.1, 3.2 нче пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

3.3.1. Кыска вакытлы, урта вакытлы һәм озак вакытлы перспективага архив эшен үстерү фаразларын, шулай ук төп эшчәнлек юнәлешләрен эшли.

3.3.2. Татарстан Республикасында архив эше торышына анализ үткәрә.

3.3.4. Архив эшен үстерү буенча федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруны оештыра.

3.3.5. Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә мәгълүматлаштыруны үстерүне, архив документлары буенча мәгълүмат эзләүне тәэмин итү өчен мәгълүматлар базаларын төзүне оештыруны тәэмин итә.

3.3.6. Архив эше өлкәсендә законнарны камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерли.

3.3.7. Архив эше өлкәсендә норматив хокукый актлар проектларын, архив хезмәтен үстерү турында тәкъдимнәр әзерләүне һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карап тикшерүгә кертүне тәэмин итә.

3.3.8. Архив эше буенча мәҗбүри үтәлергә тиешле норматив-методик документларны эшли һәм билгеләнгән тәртиптә раслый.

3.3.9. Үз компетенциясе чикләрендә архив эше мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр һәм методик әсбаплар эшли һәм раслый.

3.3.10. Татарстан Республикасы бюджеты проектына Дәүләт комитетын һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләрен тоту өлешендә тәкъдимнәр әзерли.

3.3.11. Татарстан Республикасының дәүләт милкендә булган архив документларын һәм архив фондларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыра.

3.3.12. Татарстан Республикасы территориясендә архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру кагыйдәләрен үтәүне һәм бердәм принципларын кертүне тәэмин итә.

3.3.13. «Татарстан Республикасы Архив фонды һәм архивлар турында» Татарстан Республикасы Законының үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшерүдә тота, шул исәптән архив эше өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәүгә, архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану кагыйдәләрен үтәүгә тикшерүләрне оештыра һәм гамәлгә ашыра.

3.3.14. Җирле үзидарә органнарына бирелгән архив эше өлкәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында документларга һәм мәгълүматка тикшерүләр, соратып алулар үткәрү юлы

белән тикшерүдә тота.

3.3.15. Документларның фәнни һәм гамәли әһәмиятенә экспертиза оештыра, аларны Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертү турындагы мәсьәләләрне хәл итә, документларны сайлап алу, әзерләү һәм даими саклауга тапшыруны тикшерүдә тота.

3.3.16. Татарстан Республикасында архивларны туплау чыганакларының җыелма исемлеген алып бара.

3.3.17. Архив документларын аеруча кыйммәткә ия һәм уникаль документларга кертүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә.

3.3.18. Татарстан Республикасы Архив фонды документларын үзәкләштереп дәүләт исәбенә куюны алып бара, шул исәптән электрон рәвештә.

3.3.19. Татарстан Республикасы Архив фонды документларын исәпкә алу буенча мәгълүматларны Федераль архив агентлыгына кертә.

3.3.20. Татарстан Республикасы Архив фондының Республика уникаль документлар реестрын алып бара.

3.3.21. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары составы һәм эчтәлеге турында мәгълүмат эзләүне тәэмин итү өчен мәгълүматлар базаларын, архив белешмәлекләренең башка төрләрен төзүне оештыра.

3.3.22. Татарстан Республикасы Архив фонды өчен әһәмияткә ия, Татарстан Республикасыннан читтә, шул исәптән чит илдә булган архив документларын билгеләнгән тәртиптә ачыклауны һәм сатып алуны оештыра.

3.3.23. Архив эше өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыра, Россия Федерациясенең башка төбәкләре һәм башка дәүләтләрнең архив учреждениеләре белән эшлекле элемтәләр урнаштыра, архив эше мәсьәләләре буенча халыкара оешмалар, киңәшмәләр, конференцияләр эшендә, халыкара мәгълүмат алышуда катнаша.

3.3.24. Дәүләт комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең башка субъектлары, чит ил дәүләтләренең хакимият органнары белән Татарстан Республикасы арасындагы килешүләр (шартнамәләр) проектларын әзерләүдә билгеләнгән тәртиптә катнаша, үз компетенциясе чикләрендә күрсәтелгән килешүләр (шартнамәләр) буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә, Россия Федерациясенең башка субъектлары башкарма хакимият органнары белән архив эше өлкәсендә килешүләр төзи.

3.3.25. Аукцион яки комиссия сатуында булган очракта, хосусый милектәге архив документларын сатып алуга Татарстан Республикасының өстенлекле хокукын тәэмин итү чараларын тормышка ашыра.

3.3.26. Дәүләт архивларының фәнни-тикшеренү һәм методик эшен яраштыра һәм юнәлтә, Идел буе федераль округының Архив учреждениеләре фәнни-методик советы эшендә катнаша, архив алып бару, документлар алып бару, археография мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләрне архив эше тәҗрибәсенә кертү чараларын эшли.

3.3.27. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле

үзидарә органнары эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүдә катнаша.

3.3.28. Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Татарстан Республикасы Архив фонды документларыннан һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларда саклауда булган башка архив документларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә оештыра, шул исәптән архив документлары буенча мәгълүмат эзләү системаларын төзү һәм алып бару юлы белән.

3.3.29. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең сорауларын үтәүне гамәлгә ашыра.

3.3.30. Чит ил дәүләтләренә җибәрелә торган архив белешмәләрен билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра.

3.3.31. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне тотуга һәм Дәүләт комитетына йөкләнгән функцияләрне башкаруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче һәм аны алучы функцияләрен гамәлгә ашыра.

3.3.32. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне, архив һәм тарих юнәлешендәге вакытлы басмаларны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара, шул исәптән:

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү, ябу турындагы карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

ведомство буйсынуындагы учреждениегә дәүләт учреждениесе уставында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары проектларын эшли;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне ел саен үткәрә;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен бәяләүне үткәрә.

3.3.33. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген оештыруны, аларның эшләвен тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук үз компетенциясе чикләрендә муниципаль архивларга эшчәнлекләрен методик тәэмин итүдә булышлык күрсәтә.

3.3.34. Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, казна предприятиеләрен кертеп, һәм Татарстан

Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген архив эше өлкәсендә оештыру-методик тәэмин итүне һәм документлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

3.3.35. Оешмалар архивлары, шул исәптән шәхси состав буенча архивлар эше белән тармакара оештыру-методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра.

3.3.36. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бюджеттан тыш акча җәлеп итү эшчәнлеген, шул исәптән физик һәм юридик затларга түләүле хезмәтләр күрсәтү эшен яраштыруны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.3.37. Татарстан Республикасы Архив фонды документлары нигезендә тарихи-документаль күргәзмәләр, фәнни-белешмә басмалар чыгаруны әзерләү буенча ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген оештыра.

3.3.38. Дәүләт комитеты һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеге өлкәсендә конференцияләр, семинарлар, укытулар, күргәзмәләр һәм башка чаралар оештыра.

3.3.39. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең эш тәҗрибәсенә документларны саклау, реставрацияләү, консервацияләү, күчермәләрен алу, файдалану һәм саклау буенча иң рациональ системаларны кертүне; ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне матди-техник тәэмин итү буенча чаралар күрүне оештыра.

3.3.40. Архив эше һәм эш башкару өлкәсендә ведомство буйсынуындагы оешмаларның фәнни-тикшеренү һәм методик эшен оештыра.

3.3.41. Дәүләт комитеты һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр кадрларын, шулай ук дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар архивлары хезмәткәрләрен билгеләнгән тәртиптә әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификацияләрен күтәрүне оештыра.

3.3.42. Татарстан Республикасы Архив фонды фондлары һәм документлары буенча тармак һәм тармакара мәгълүмат системаларын, мәгълүматлар базаларын һәм банкларын, архив белешмәлекләрен эшләүне, кертүне һәм тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

3.3.43. Документлар белән идарә итү системасын камилләштерү максатларында, дәүләт органнарында документлар эшләү процессын һәм документлар әйләнеше күләмен мониторинглауны гамәлгә ашыра.

3.3.44. Билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат-реклама эшчәнлеген, массакүләм мәгълүмат чаралары (шул исәптән электрон) белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

3.3.45. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны йөртүчеләрнең яшерен булуын билгеләнгән тәртиптә бетерү буенча ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең эшчәнлеген оештыра.

3.3.46. Дәүләт комитетының, ведомство буйсынуындагы оешмаларның, эшчәнлекләре Дәүләт комитеты эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагындагы өлкәгә караган оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук әлеге чараларны методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

3.3.47. Сугыш вакытына Татарстан Республикасы Архив фондының уникаль һәм аеруча кыйммәткә ия документларын саклау буенча мобилизация йөкләмәсен планлаштыруны һәм үтәлешен тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

3.3.48. Гражданнар оборонасы мәсьәләләрендә Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Дәүләт архивы хезмәткәрләрен һәм аларның гаилә әгъзаларын кирәк булган очракта планлаштырылган шәһәр чите зонасына эвакуацияләү планын эшләүне тормышка ашыра.

3.3.49. Үз компетенциясе чикләрендә дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны саклауны тәэмин итә. Ведомство буйсынуындагы оешмаларда һәм эшчәнлекләре Дәүләт комитеты эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагындагы өлкәгә караган оешмаларда дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны саклау өлкәсендәге чараларны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра, шулай ук әлеге чараларны методик тәэмин итүне тормышка ашыра.

3.3.50. Дәүләт комитеты компетенциясенә, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр, гаризалар, мөрәҗәгатьләр, шикаятьләр карап тикшерүне һәм гражданнарны кабул итүне оештыра, алар буенча кирәкле чаралар күрә.

3.3.51. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегендә юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен, гаризаларын, мөрәҗәгатьләрен һәм шикаятьләрен үз вакытында карауны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.3.52. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең хезмәтне саклау эшен яраштыра, хезмәтне саклау өчен җаваплы вазыйфаи затларны укытуны оештыра.

3.3.53. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Дәүләт комитетының эшчәнлек өлкәсендә максатчан республика программалары һәм проектларының дәүләт заказчысы функциясен гамәлгә ашыра, дәүләт ихтыяҗлары һәм Дәүләт комитеты, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, хезмәтләр күрсәтүгә, эшләр башкаруга заказлар урнаштыруны һәм дәүләт контрактлары төзүне гамәлгә ашыра.

3.3.54. Үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләр, килешүләр һәм гавами-хокукый характердагы башка актлар реестрын алып бара.

3.3.55. Ел саен 1 февральгә кадәр коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы вәкаләтле органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап тапшыра.

3.3.56. Дәүләт комитеты коллегиясе, Дәүләт комитетының фәнни советы, Дәүләт комитетының эксперт-тикшерү методик комиссиясе, Дәүләт комитеты каршында төзелә торган башка комиссияләр һәм эшче төркемнәр эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

3.3.57. Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен тапшыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.3.58. Проект документларын эшләүне оештыра, ведомство буйсынуындагы оешмалар объектларын төзүне финанслауны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы Архив фонды документларын саклауны, туплауны һәм файдалануны яхшырту максатларында, аларга урыннарны һәм башка мөлкәтне

бирү, алар арасында бүлү һәм яңадан бүлү турында тәкъдимнәр әзерли.

3.3.59. Федераль дәүләт хакимияте органнары – дәүләт архивларын туплау чыганакларының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ликвидация комиссияләре эшендә катнаша.

3.3.60. Дәүләт комитеты һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган һәм оператив идарә итү хокукында аларга беркетелгән объектларның (территорияләрнең) сакланышына таләпләрне үтәүне оештыра һәм тәэмин итә.

3.3.61. Үз компетенциясе чикләрендә террорчылыкка каршы торуда, шул исәптән террорчылыкка каршы тору чараларын тормышка ашырганда укытулар үткәрүдә катнаша.

3.3.62. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында күздә тотылган булса, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 4. Дәүләт комитетының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Дәүләт комитеты билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә үзенең функцияләрен гамәлгә ашыру максатларында түбәндәге хокукларга ия:

4.1.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт оешмаларыннан һәм муниципаль оешмалардан, шулай ук башка оештыру-хокукый формадагы оешмалардан архивлар эше һәм торышы һәм эш башкаруда документлар белән эшләүне оештыру турында кирәкле материалларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга.

4.1.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар вәкилләрен архивлар эше һәм эш башкаруда документлар белән эшләүне оештыру мәсьәләләре буенча тыңларга.

4.1.3. Үз компетенциясе чикләрендә архивларны туплау чыганаклары булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмаларга мәҗбүри үтәлергә тиешле архив эше һәм эш башкаруда документлар белән эшләүне оештыру буенча язма күрсәтмәләр, архив законнарын, архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану кагыйдәләрен бозуларны бетерү турында боерыклар бирергә.

4.1.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча һәм гамәлдәге законнар нигезендә ведомство буйсынуындагы оешмалар төзергә.

4.1.5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына архив эше мәсьәләләре буенча федераль законнарга һәм республика законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына каршы килгән норматив хокукый актларны гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәр кертергә.

4.1.6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Дәүләт комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар проектлары кертергә.

4.1.7. Функцияләрен гамәлгә ашырганда федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итәргә.

4.1.8. Җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында законнарда билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

4.1.9. Архив эше турындагы законнарны үтәү эшчәнлегенә карата тикшерүләр үткәрү максаты белән, архивларны туплау чыганаклары булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының, шулай ук оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмаларның архивларына һәм структур бүлекчәләренә билгеләнгән тәртиптә барырга.

4.1.10. Архив эше өлкәсендәге административ хокук бозулар турында беркетмәләр рәсмиләштерергә.

4.1.11. Архив эше өлкәсендәге закон актларын һәм башка норматив актларны бозган өчен юридик һәм физик затларны билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тарту өчен хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә.

4.1.12. Аңа оператив идарә итүгә бирелгән дәүләт мөлкәте белән билгеләнгән тәртиптә идарә итүне гамәлгә ашырырга.

4.1.13. Граждан законнары нигезендә хуҗалык һәм башка гражданлык-хокукый шартнамәләр, килешүләр төзергә.

4.1.14. Законнарга ярашлы рәвештә товарлар кайтарту, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү өчен контракт нигезендә махсуслаштырылган оешманы җәлеп итәргә.

4.1.15. Электрон имза, электрон эш башкару системаларын, шулай ук башка электрон системаларны кулланырга.

4.1.16. Гомуми юрисдикция судларында һәм арбитраж судларда як буларак чыгыш ясарга.

4.1.17. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре һөнәр берлегенең республика комитеты белән тармак килешүе төзергә.

4.1.18. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына аеруча уңыш казанган хезмәткәрләрне дәүләт бүләкләренә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен бирүгә тәкъдим итү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

4.1.19. Дәүләт комитетының ведомство бүләкләрен расларга һәм алар белән бүләкләү турында карарлар кабул итәргә. Федераль архив агентлыгына аеруча уңыш казанган хезмәткәрләрне ведомство бүләкләренә тәкъдим итү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

4.1.20. Билгеләнгән тәртиптә бюллетеньнәр, җыентыклар һәм башка басмалар чыгарырга, архив һәм тарих юнәлешендәге вакытлы басмаларны гамәлгә куючы булып торырга.

4.1.21. Дәүләт комитеты һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең

эшчәнлек өлкәсенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен фәнни һәм башка оешмаларны, галимнәрне һәм белгечләрне билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

4.1.22. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә киңәшмә һәм эксперт органнары (советлар, комиссияләр, төркемнәр, коллегияләр) төзергә.

4.2. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары аларга йөкләнгән бурычларны бозган яки тиешенчә үтәмәгән өчен законнар нигезендә җавап тота.

## 5. Дәүләт комитеты эшчәнлеген оештыру

5.1. Дәүләт комитетын рәис җитәкли, ул Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә вазыйфасына билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә.

Дәүләт комитеты рәисенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе тәкъдиме буенча вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган ике урынбасары була.

5.2. Дәүләт комитеты рәисе:

5.2.1. Дәүләт комитеты эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм Дәүләт комитетына йөкләнгән бурычларның үтәлеше һәм үзенең функцияләрен гамәлгә ашыру өчен шәхси җавап тота.

5.2.2. Башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары һәм дәүләткә карамаган оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр белән мөнәсәбәтләрдә Дәүләт комитеты исеменнән эш итә.

5.2.3. Урынбасарларының бурычларын билгели.

5.2.4. Билгеләнгән хезмәткәрләр саны һәм хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә Дәүләт комитетының, ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең штат расписаниесен, тиешле чорга расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Дәүләт комитетын, ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне тотуга керемнәр һәм чыгымнар сметасын раслый.

5.2.5. Түбәндәгеләрне билгеләнгән тәртиптә вазыйфага билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә:

Дәүләт комитеты хезмәткәрләрен;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен.

5.2.6. Дәүләт комитеты рәисе урынбасарлары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый.

5.2.7. Дәүләт комитетына беркетелгән функцияләрне башкару процессларын (ярдәмче процессларын) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә.

5.2.8. Нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә Дәүләт комитеты рәисе урынбасары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында Дәүләт комитеты буенча нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән күрсәткечләренә бәйле рәвештә стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү хакындагы нигезләмәне боерыгы белән раслый.

5.2.9. Дәүләт комитеты өчен билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезндә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.

5.2.10. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле боерыклар чыгара, күрсәтмәләр бирә, кагыйдәләр, нигезләмәләр, инструкцияләрне раслый, аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыра.

5.2.11. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр актларын, әгәр алар федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Дәүләт комитетының хокукый актларына каршы килсә, гамәлдән чыгарырга хокуклы.

5.3. Дәүләт комитеты тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе (коллегия рәисе), вазыйфа буенча аның урынбасарлары һәм башка затлар составында коллегия төзелә.

Коллегия составы һәм әгъзалары саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Киңәшмә органы булып торган Дәүләт комитеты коллегиясе Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә дәүләт идарәсенең иң мөһим мәсьәләләрен карап тикшерә. Коллегия аның турындагы нигезләмә нигезендә эшли. Коллегия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Дәүләт комитеты каршында түбәндәгеләр эшли:

Татарстан Республикасында архив эше өлкәсендә фәнни проблемаларны карап тикшерү буенча фәнни-консультатив совет;

документларның кыйммәтенә экспертиза үткәрү, аларны Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертү, составында уникаль документларны билгеләү белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү, архив эше өлкәсендә методик һәм гамәли мәсьәләләрне хәл итү өчен эксперт-тикшерү һәм методик комиссия.


Фәнни-консультатив совет, эксперт-тикшерү һәм методик комиссия турындагы нигезләмәләр һәм аларның составлары Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан раслана.

## 6. Дәүләт комитетын оештыру, үзгәртеп оештыру һәм ябу

Дәүләт комитетын оештыру, үзгәртеп оештыру һәм ябу гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 август, 541 нче карары белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ СТРУКТУРАСЫ**




___